**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2024 **Чирмешән авылы** **№ 380**

**Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2024 елның 29 маендагы «2024 елның II яртыеллыгына Чирмешән муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында» 191 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «2024 елга торак урынны карап тоту өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән түләү күләмнәрен мониторинглау нәтиҗәләре турында» 2024 елның 6 сентябрендәге 04-04/11740 номерлы хатын карап, **КАРАР БИРӘМ:**

1. Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2024 елның 29 маендагы «2024 елның II яртыеллыгына Чирмешән муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында» 191 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 2 һәм 3 абзацларын «2024 елның 1 июленнән 2024 елның 31 декабренә кадәр расларга һәм гамәлгә кертергә» дип яңа редакциядә бәян итәргә:

- Чирмешән муниципаль районы муниципаль торак фондының торак урыннарын яллаучылар һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайламаган торак урыннар милекчеләре өчен, торак йорт белән идарә итү ысулын сайлаган күпфатирлы торак йорттагы торак урыннар милекчеләре өчен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар һәм (яисә) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмнәре (1 нче кушымта);

- 1 пунктның 4 абзацын үз көчен югалткан дип санарга;

- 1 пунктның 5 абзацын тиешенчә «4» абзац дип санарга (2 нче кушымта)

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.Г. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М. Җамалетдинов